# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ШӘҺӘР ТАТАРЛАРЫНДА ИМИНИЯТ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Л.Р. Габдрафикова****, тарих фәннары докторы*

# INSURANCE AMONG URBAN TATARS IN THE LATE 19TH - EARLY 20TH CENTURY

***L.R. Gabdrafikova***

Русиядә беренче иминият җәмгыяте 1827 елда барлыкка килә һәм янгыннардан соңгы бөлгенлекне җиңеләйтүне күзаллый. XIX гасыр урталарында йорт-җирләрне иминиятләү шәһәрләрдә шактый таралган була һәм, әлбәттә, бу гадәткә күп кенә шәһәр татарлары да кушыла. Бу аларның гомумән торак-җиргә һәм мөлкәткә булган мөнәсәбәтләре үзгәрү белән бәйле, шул ук вакытта буржуаз заманда яшәүче мөселман кешесенең фикер йөртүе инде башкача булуга ишарәли.

Архив фондларында иминият белән бәйле бик күп документлар сакланып калган. Мәсәлән, Казанда яшәгән сәүдәгәр Айтугановлар гаиләсенең утары 1891 елда «Казанда үзара иминиятләштерү җәмгыяте» («Общество взаимного страхования имуществ в Казани») дигән җәмгыятьтә 22 мең сум бәрабәренә иминиятләштерелгән була[1]. Билгеле ки, алдынгы карашлы, бай һәм мөхтәрәм татар сәүдәгәрләре Айтугановлар гаиләсеннән татар дөньясында шактый билгеле шәхесләр чыккан. Өммегөлсем Айтуганова тарихчы Газиз Гобәйдуллиның әнисе, ә аның сеңлесе Бибигайшә – галим Гали Рәхимнең әнисе. Башка шәһәрләрдә яшәүче татар байлары да йорт-җирләренә иминият таныклыгы алуны мәслихәт күрәләр. Мәсәлән, 1885 елда Сембер сәүдәгәре Шәмсетдин Абушаев ике катлы йортын 21 мең сумга иминиятләгән, шул ук вакытта бу бина 150 мең сумга бәяләнгән була[2].

XIX гасыр ахырында иминият җәмгыятьләре күбәя, алар арасыннан уңайлырагын сайлап алу мөмкинлекләре дә арта. Йортларын янгыннан саклау өчен бу җәмгыятьләргә бай гаиләләр генә түгел, ә бик үк хәлле булмаган катлам кешеләре дә мөрәҗәгать итә башлый. Мәсәлән, ун ел дәвамында Казандагы Яңа бистәдәдән Г.Гомәрева дигән мещан хатыны кечкенә агач йортын «Страховое от огня товарищество Саламандра» ширкәтендә иминиятләп килә. Бу ханым ел саен иминият ширкәтенә 4 сум түли, өч бүлмәле йорты исә 200 сумга бәяләнгән була[3].

Татарлар арасында иминиятчеләр саны XX гасыр башында шактый күбәя. Казанда 1879 елдан алып «Агентство московского страхового от огня общества» эшләп килә, 1903 елдан

башлап бу җәмгыятькә мөрәҗәгать итүчеләр арасында күп кенә танылган татар гаиләләре исемнәре күренә – Алкиннар, Апанаевлар, Әхмәровлар, Кашаевлар, Сәйдәшевлар, Хөсәеновлар. Иминият бәясе йортның кайда урнашуыннан бәйле булган. Мәсәлән, агач төзелешләр шактый булган һәм шул сәбәпле янгын чыгу ихтималы күбрәк булган җирләрдә иминиятләү хакы кыйммәтрәк чыккан. Эшмәкәрләр арасында йорт-җирләрен генә түгел, сәүдә бүлмәләрен һәм сатуга алынган товарларын да иминиятләү гадәте тарала[4].

Кайбер кешеләр бу юнәлештә шункадәр тырышалар ки, хәтта торак-җирләрен берничә урында иминиятләп куялар. Әмма бу очракта иминият түләүләреннән бөтенләй мәхрүм калучылар да була. Казан шәһәреннән Гафуров, мәсәлән, шулай үз йортын ике җәмгыятьтә иминиятләштереп куя, тик янгыннан соң берсеннән дә торак-җирен торгызу өчен акча ала алмый, чөнки билгеле кагыйдәләрне бозган санала һәм аның бу «тырышлыгы» иминият җәмгыятьләрендә шик тудыра[5]. Бу очраклы гына күренеш түгел, чөнки акча белән бәйле эшләрдә җиңел юллар белән баерга теләүчеләр дә күренә башлый. Янгыннардан соң йорт-җиренә иминият таныклыгы булган хуҗаларга шикләнеп карыйлар. Кайчагында мөлкәтне иминиятләштерү нахак гаепләүләргә дә китерә. Мәсәлән, 1906 елда Казан шәһәрендә яшәүче сәүдә эшләре белән көн күргән З.Ногмановны күршеләре үз йортына үзе ут төрткән дип судка бирәләр. Күршеләр аны бу эшне 3500 сумлык иминият премиясен алыр өчен эшләгән дип фаразлыйлар. Ногмановның йорт-җиреннән чыккан янгын күрше йортларга да күчә. Кызганычка каршы, әлеге йортлар иминиятләштерелмәгән була. Аралары шактый гына бозылышкан күршеләр суд вакытында Ногмановның үзенең дә янгыннан зур зыян күргәнен ачыклыйлар: әлеге янгын вакытында сәүдәгәрнең 3500 сумга бәяләнгән йорты эчендә сатуга әзерләнгән 6 мең сумлык товары да янып бетә[6].

1905 елдан соң татар гәзитләрендә иминият җәмгыятьләренең рекламалары да күренә башлый. Мәсәлән, «Саламандра» һәм «Россия» иминият агентлыкларының игъланнары «Әл-Ислах» гәзитендә еш очрый. Бу вакытлы матбугат басмасын күбесенчә яшьләр һәм аеруча шәкертләр яратып укыйлар[7].

Иминиятнең татарлар арасында шактый таралуын бу юнәлештәге җәмгыятьләрдә һәм ширкәтләрдә мөселман исемнәре булу да исбатлап тора. XX гасыр башында Мөхәммәтҗан Сәйдәшевне һәм Габдулла Апанаевны «Казанское городское общество взаимного от огня страхования» җәмгыяте идарәсенә әгъза итеп сайлыйлар. 1914 елда Габдулла Апаневны сайлау алдыннан иминиятче-татарлар идарәдә, һичшиксез, мөселман кешесе булу мәслихәт дигән фикергә киләләр[8]. Бу оешма шәһәр җәмгыяте ихтыяры белән

ачылган. Моннан тыш, татарлар шәхси иминият оешмаларында да эшлиләр. Мәсәлән, 1914 елда Уфада «Якорь» иминият җәмгыятенең агенты булып чыгышы белән сәүдәгәр гаиләсеннән булган Хәсән Кәримов эшли[9].

Шулай да әлеге социаль чарага каршы торган мөселманнар да очрый. Шуңа күрә алдынгы карашлы дин әһелләре йорт-җирне иминиятләштерү гадәтен яклап чыгалар. Мәсәлән, 1910 елда атаклы ишан Зәйнулла Рәсүлев Троицк шәһәренең (Оренбург губернасы) мөселман җәмәгатенә адресланган вәгазендә кешенең үзенең гомерен һәм мөлкәтен бәхетсез очраклардан иминиятләштерүе исламга каршы килми дигән фикерне җиткерә[10].

Берничә елдан соң бу күренешнең татар җәмгыятендә гадәти төс алганлыгы хәтта шәһәрдә яшәүче дин әһелләренең дә милек һәм йортларын иминиятләштерүләреннән күренә. 1916 елда Казан шәһәренең 17 нче җәмигъ мәчете мулласы Мөбарәкҗан Мансуров Яңа бистәдәге йортын «Якорь» җәмгыятендә 3 мең сумга иминиятләштерә[11]. Өяз шәһәрләрендә дә милек-мөлкәтне иминиятләштерүне күпләр хуплыйлар. Мәсәлән, Чистай татарлары урындагы кайбер мөселман җәмәгать биналарын, мәчет, мәктәп һәм мәдрәсәләрне «Чистопольское отделение Казанского городского общества взаимного от огня страхования» оешмасында иминиятләштереп куялар[12].

Йорт-җир һәм сату товарлары белән беррәттән, шәһәр халкы аеруча кыйммәтле күчмә милекне дә иминиятләргә тырыша. Йорт җиһазлары белән бергә кием-салым, савыт-саба, музыка уен кораллары һәм башка әйберләрне иминиятләгәннәр. Кайбер кешеләр бик сирәк очрый торган кыйммәтле предметларны да янгын бәласеннән сакларга тырышкан. Татарлар арасыннан чыккан беренче профессиональ фотограф Габделгазый Миңнегалиев 1903 елдан башлап үзенең фотоаппаратын һәм аның җиһазларын ун ел дәвамында «Московское страховое от огня общество»сының Казан бүлегендә иминиятләп килә. Г.Миңнегалиевның Казанда үз йорты булмый, фатир яллап яши, әмма фотоаппаратын иминиятләргә онытмый, чөнки ул аның иң төп һәм кадерле эш коралы була[13].

XX гасыр башында мөселманнар арасында йорт-җир һәм башка төрле милектән тыш, кешенең гомерен иминиятләү дә күпмедер дәрәҗәдә тарала. «Казан» милли-мәдәни үзәкнең Милли мәдәният музеенда бик кызыклы бер экспонат – сәүдәгәрләр токымынан булган Ибраһим Исхак улы Апанаевның «страхование на случай смерти» дигән таныклыгы саклана. 37 яшьлек бай 1913 елда үзенең гомерен «Первое Российское Страховое общество» оешмасында 6000 сумга 1936 елга кадәр иминиятләгән[14]. Билгеле инде, бу таныклык биш елдан соң яраксызга әйләнә, әмма тормыш гадәти рәвештә барган булса, Апанаевның туганнары яисә балалары ул үлгәндән соң ярдәмсез калмаслар иде.

Бу заманда ялланып эшләгән эшчеләрне дә хуҗалары тарафыннан мәҗбүри рәвештә иминиятләү җайга салына башлый. Россиядә эшчеләрне бәла-казадан яисә саулыгы нык какшау очракларыннан социаль иминиятләү системасы 1912 елда кертелә. Шул вакыттан бирле эшчеләрнең хезмәт хакларыннан социаль фондларга акча алып кала башлыйлар һәм шулай ук эшчеләрнең хуҗасы да әлеге фондка үз өлешен кертеп бара[15]. Эшләгән урыннарында бәхетсезлеккә очрап сәламәтлеген югалткан яисә бакыйлыкка күчкән эшчеләр мәсьәләсе XX гасыр башында бик кискен проблемага әйләнә. Аларның гаиләләре, ә кайбер очракта эш урынында гарипләнгән кеше үзе дә, элекке хуҗасы исеменә күп хатлар язып, акчалата ярдәм сорап үтенеп йөриләр. Әмма бу үтенечләргә җавап бирүче табылса да, күрсәтелгән ярдәм даими рәвештә бирелми, ә бары тик бер генә тапкыр күрсәтелә. Мондый сәдака гына, әлбәттә, бәлагә очраган гаиләнең мөшкел хәлен артык үзгәртә алмый. Менә шул чорда, 1912 елда, социаль иминиятләү булдырыла. Ә Ибраһим Апанаев кебек үзенә үзе хуҗалар, үз гомерләрен үзләре иминиятләштереп, язмыш җилләреннән ничектер сакланып калырга тырышалар.

Совет чорында эшчеләрне социаль иминиятләү дәвам ителә һәм гадәти күренешкә әверелә. Мирасханәдә 1923 елда Фатыйх Әмирханга бирелгән иминләштерелгән затның шәхси кенәгәсе бар. Бу 7040 нчы санлы документ язучыга Татар театр техникумының укытучысы буларак бирелгән, аның буенча ул бушлай медицина ярдәме һәм иминият пособиеләрен ала алган[16].

Әмма бу рәвешле социаль яклау кергәнче, күп еллар дәвамында ирекле һәм шәхси иминиятләү эшләп килгән. XIX гасырның икенче яртысыннан мал-мөлкәтне иминиятләштерү шактый көчәя, шәһәр халкы күчемсез милек белән беррәттән, башка төрле әйберләрне дә иминиятләүне хуп күрә башлый. Моннан тыш, үз гомерләре һәм сәламәтлекләре өчен дә иминият таныклыгы алып куючылар була. Шулай итеп, милек-мөлкәте булган күпчелек татарлар өчен иминиятләштерү шәһәр тормышының мәҗбүри элементына әйләнә.

Әлеге гамәл киң таралу белән, аны «мөселманлаштыру», ягъни мөселман иминият җәмгыятен оештыру фикере туа. Мөселманнарның үзара ярдәмләшүләре мәслихәт дигән фикер иң элек «Тәрҗеман» газитендә күренә[17]. 1911 елда «Общество Братского Взаимного страхования «Мусульманин» дигән оешма мөселман халыкларына иминиятәштерүдә үзенең булышлыгын тәкъдим итеп карый[18]. Исеменнән күренгәнчә, ул мөселман җәмгыяте әгъзаларының үзара ярдәмләшүләренә исәпләнгән була. Бу җәмгыятьнең игъланы рус телендә чыккан «Мусульманин» журналында басыла, әмма бу басма бик озын гомерле булмый һәм җәмгыять тә укучылар арасында әллә ни таралыш алмый. Күрәсең, һәр төбәктә булган төрле иминият

җәмгыятьләре, мөселманнарныкы гына булмаса да, шәһәр татарларының ихтыяҗларын канәгатьләндергәннәр.

Кешеләрнең үз гомерләрен һәм милекләрен матди ресурслар белән якларга тырышуы – буржуаз мөнәсәбәтләрнең иң билгеле үрнәге. Бу күренеш XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында шактый үсеш алган, шәһәр халкы арасындагы мөнәсәбәтләр инде туганлык, күршеләр яисә башка төрле җәмәгать ярдәме белән генә билгеләнмәгән, беренче чиратта акча һәм товар алмашудан гыйбарәт булган. Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасы бу мөнәсәбәтләрне сатирик планда сурәтләгән мисалларның берсе дисәк тә була. Шәһәр татарлары туганнар яки мәхәллә ярдәменә ышанып тормаганнар, беренче чиратта үз көчләренә таянганнар. Шуңа күрә үзләрен һәм гаиләләрен төрле тормыш бәхетсезлекләреннән иминиятләштерү ярдәмендә якларга тырышканнар.

Кулланылган кыскартылмалар

УӨДА – Ульяновск өлкәсе дәүләт архивы (Государственный архив Ульяновской области).

“Казан” ММҮ МММ (МНК НКЦ «Казань») – “Казан” милли-мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музее (Музей национальной культуры Национального культурного центра «Казань»).

ТР ДА – Татарстан Республикасы дәүләт архивы (Государственный архив Республики Татарстан).

ЯһММҮ (ЦПиМН) – ТР ФА Г.Ибраһимов ис. тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге (Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусств им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан).

ПРИМЕЧАНИЯ

(Endnotes)

1 ТР ДА, 139 фонд, 1 тасв., 240 эш, б. 48.
2 УӨДА, 1 фонд, 16 тасв., 224 эш, б. 6.
3 ТР ДА, 139 фонд, 1 тасв., 212 эш, б. 5-42.
4 ТР ДА, 165 фонд, 15 тасв., 1 эш; 19 тасв., 1, 3, 20 эшләр; 20 тасв., 21 эш; 21 тасв., 5 эш; 22 тасв., 14 эш; 28 тас. 7 эш.
5 Казанский телеграф. – 1900. – 25 августа. – № 2344.
6 ТР ДА, 41 фонд, 4 тасв., 616 эш, б. 18.
7 Әл-ислах. – 1908. – №39; Әл-ислах. – 1909. – № 56.
8 ТР ДА, 1 фонд, 4 тасв., 6554 эш, б. 2.
9 Адрес-календарь Уфимской губернии на 1914 год. – Уфа, 1914. С. 88.
10 Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Челябинского края (XVIII – начало XX в.). М., 2011. С. 61.
11 ТР ДА, 138 фонд, 1 тасв., 275 эш, б. 3.
12 ТР ДА, 786 фонд, 1 тасв., 17, 18, 19 эшләр.
13 Габдрафикова Л. Жил-был фотограф один… // Казань. 2016. №2. С. 44–46.
14 “Казан” ММҮ МММ, КП-13470.
15 Вигдорчик Н.А. Страхование на случай болезни в России. Краткое руководство для врачей. – СПб., 1914. С. 3.
16 ЯһММҮ, 16 фонд, 2 тасв., 10 эш, б. 1.
17 Тарджеман. – 1903. – 16 июня. - №23.
18 Мусульманин. – 1911. – май. - №8–10, с. 444.

**Сведения об авторе:** Габдрафикова Лилия Рамилевна, доктор исторических наук, главный научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов Республики Татарстан Института истории им. Ш.Марджани АН РТ, e-mail: bahetem@mail.ru

**Аннотация:** В статье на основе широкого круга архивных документов рассматривается распространение различных видов страховых услуг среди городских татар: страхование жилья, имущества, здоровья и жизни. С развитием городской инфраструктуры менялся образ жизни горожан, бытовые мелочи отражали мировоззренческие противоречия, охватившие татарское общество в конце XIX – начале XX вв.

**Ключевые слова:** страхование, пожарная безопасность, городские татары, ислам, городская культура, буржуазное общество, история повседневности.

**Abstract:** The article based on archival documents examines the needs of city Tatars to various types of insurance services: insurance of housing, property, health and life. With the development of urban infrastructure has changed the way of life of citizens. Domestic details of everyday life were expressed in the ideological contradictions that gripped the Tatar society in the late 19th and early 20th centuries.

**Key-words:** insurance, fire safety, urban Tatars, Islam, urban culture, bourgeois society, history of everyday life.